**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 3 октябрь | № 740

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәр белеме бирүче «Чистай педагогика көллияте» дәүләт автоном белем учреждениесен һәм урта һөнәр белеме бирүче «Чистай политехника көллияте» дәүләт автоном белем учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2014 ел, 12 декабрь, 980 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Урта һөнәр белеме бирүче «Чистай педагогика көллияте» дәүләт автоном белем учреждениесен һәм урта һөнәр белеме бирүче «Чистай политехника көллияте» дәүләт автоном белем учреждениесен үзгәртеп оештыру турында» 2014 ел, 12 декабрь, 980 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чистай күпюнәлешле көллиятенә аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган, элек Чистай педагогика һәм Чистай политехника көллиятләренә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында 30 көн эчендә беркетергә, Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 15 йорт, (педагогика училищесы һәм остаханәләр); Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 40 йорт, (тулай торак – 40/1 йорт, тулай торак– 40/2 йорт, тулай торак – 40/3 йорт, тулай торак – 40/4 йорт) адреслары буенча урнашкан биналардан тыш»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә (алга таба – Музей) оператив идарә хокукында дәүләт мөлкәтен – Чистай шәһәре, К.Маркс урамы,

15 йорт, (педагогика училищесы һәм остаханәләр); Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 40 йорт, (тулай торак – 40/1 йорт, тулай торак– 40/2 йорт, тулай торак – 40/3 йорт, тулай торак – 40/4 йорт) адреслары буенча урнашкан биналарны 30 көн эчендә беркетергә;

Музейга беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында 120 көн эчендә бирүне тәэмин итәргә.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, 60 көн эчендә һөнәри белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тоту нормативларын һәм норматив чыгымнарын билгели торган норматив хокукый актларга һәм торак булмаган фонд белән идарә итү һәм файдалану буенча Музей башкара торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарны билгеләүче норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.»;

6 пункны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына билгеләнгән тәртиптә «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 елларның планлаштырылган чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү турында тәкъдимнәр тапшырырга;

6 пунктны 7 пункт дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\740.docx